Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен
татар теленнән мәктәп олимпиадасы биремнәре
2017-2018 уку елы
8 нче сыйныф

Үткәрү вакыты – 90 минут.
Максималь балл – 45.

I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге сүз басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Кешеләр киләләр дә китәләр, ә ул үзенең язмышы белән тагын ялгыз кала. (Ф.Яруллин)

а) 2 ә) 3 б) 4 в) 1

2. Тартыклар ассимиляциясенең яңгыраулыкта охшашлануы күзәтелгән сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Ипи авырлыгыннан киштәләр сыгылган, әйтерсең бөтен дөнья байлыгы монда җыелган. (Ф.Яруллин)

а) авырлыгыннан, байлыгы
ә) сыгылган
б) сыгылган, монда, җыелган
в) авырлыгыннан, сыгылган, байлыгы, монда, җыелган

3. Тарихи сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) куцат, айбагар, ихата, әпәй
ә) анализ, вакланма, формула, интервал
б) мәктүп, инсан, берлән, өмит
в) кистән, шишәк, көбә, пищаль

4. Җөмләдәге алмашлыкка дөрес морфологик анализ ясалган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Үзенең йомшаклыгын таныган кеше көчле кешегә әверелә. (О.Бальзак)

а) зат алмашлыгы, берлек санда, иялек килешендә
ә) билгеләү алмашлыгы, берлек санда, иялек килешендә
б) күрсәтү алмашлыгы, берлек санда, иялек килешендә
в) тартым алмашлыгы, берлек санда, иялек килешендә

5. Җөмләдәге сан төркемчәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Песнәкләрнең уңнан тугызы суыктан түгел, ачлыктан үлә. (Календарьдан)

а) микъдар

ә) тәртип

б) чама

в) бүлем

6. Дүртюллыктагы хәл фигыльләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Өйләрдә ут сүнеп,
Урамнар тын калгач,
Кыш килгән авылга,
Кешеләр йоклагач. (Г.Сәгыйров)

а) сүнеп

ә) калгач, йоклагач

б) калгач, килгән, йоклагач

в) сүнеп, калгач, йоклагач

7. Калын хәрефләр белән бирелгән хәбәрнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Эш беткәч кенә ***тантана ит***. (И.Гёте)

а) тезмә исем хәбәр

ә) кушма исем хәбәр

б) тезмә фигыль хәбәр

в) кушма фигыль хәбәр

8. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмлә кисәгенең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Кошлар оя ***ясаучыларга*** *рәхмәт укыдылар.* (А.Алиш)

а) ия

ә) тәмамлык

б) аныклагыч

в) урын хәле

II. Теоретик бирем.

Тиңдәш кисәкләр янындагы тыныш билгеләрен аңлатып языгыз. ***(10 балл)***

III. Гамәли һәм иҗади бирем.

1. Табышмакны укыгыз, җавабын языгыз. ***(1 балл)***

Өр-яңа савыт тишелеп беткән,
Тишекләреннән ак яңгыр үткән.

2. *Савыт* сүзенә фонетик анализ ясагыз. ***(3 балл)***
3. *Өр-яңа* сүзенә морфологик анализ ясагыз. ***(2 балл)***
4. Сүзләрнең антоним парларын языгыз: ***(3 балл)***

Өр-яңа –
Ак –
Яңгыр –

5. *“Көзге яңгыр”* дигән темага 10 җөмлә языгыз. ***(10 балл)***